ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Тэмте авыл жирлеге Советы**

422824,Кама Тамагы муниципаль районы,
Тэмте авыл жирлеге, Октябрь урамы, 65

тел. (884377)31176

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Совет Теньковского**
**сельского поселения**

Камско-Устьинский муниципальный район,
Теньковское сельское поселение,
ул. Октябрьская, 65
тел. ( 884377)31176

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 26.11.2019** **№ 7**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында» 2019 елның 26 ноярендәге 6 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге башлыгы карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **КАРАР** бирәм:

1.2019 елның 9 декабрендә 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең Лабыш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. 2019 елның 9 декабрендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегенең татар зональ тәҗрибә станциясе поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

3. 2019 елның 9 декабрендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегенең Тукай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш , 300 сум күләмендә үзара салым кертү  һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә  җибәрү белән килешәсезме?:

- кышкы-җәйге чорда бистәләр эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;
- урам утларын карап тоту.

«ӘЙЕ"                                        "ЮК"

5. Әлеге карарны ,кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә, мәгълүмат стендларына һәм Тәмте авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе                                        И. А. Зиновьев